**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

06.07.2022

№ 226

**Татарстан Республикасында социаль-икътисадый тотрыклылыкны тәэмин итү буенча оператив штаб составына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында социаль-икътисадый тотрыклылыкны тәэмин итү буенча оператив штаб төзү турында» 2022 елның 29 мартындагы 125 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2022 елның 29 апрелендәге 150 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында социаль-икътисадый тотрыклылыкны тәэмин итү буенча оператив штаб (алга таба – Оператив штаб) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Оператив штаб составыннан А.Ә. Кәримовны чыгарырга;

Оператив штаб составына кертергә:

Вахитов Радик Рәфыйк улын – Россия Федерациясе Чит илләр эшләре министрлыгының Казан шәһәрендәге вәкилен (килешү буенча);

Галиев Илнур Наил улын – Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесен (килешү буенча);

Галәвов Рөстәм Әсфән улын – Татарстан Республикасында Дәүләт хезмәт инспекциясе җитәкчесе – Татарстан Республикасында баш дәүләт хезмәт инспекторын (килешү буенча);

Гәрәев Марат Мәсгут улын – Федераль таможня хезмәтенең Идел буе таможня идарәсе Татарстан таможнясы башлыгын (килешү буенча);

Гафуров Эдуард Ивановичны – Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе башлыгы урынбасары вазыйфаларын вакытлыча башкаручы – лицензия-рөхсәт кәгазьләре бирү эше үзәге башлыгын (килешү буенча);

Горев Дмитрий Александровичны – Экология, технология һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтенең Идел буе идарәсе җитәкчесе урынбасарын (килешү буенча);

Горюнова Елена Львовнаны – дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе идарәчесе урынбасарын (килешү буенча);

Григорьева Елена Ивановнаны – Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесе урынбасарын (килешү буенча);

Закиров Әнвәр Фәрит улын – Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесен – Татарстан Республикасы баш суд приставын (килешү буенча);

Закиров Фердинат Равил улын – дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлекчәсе идарәчесе вазыйфаларын башкаручыны (килешү буенча);

Җәббаров Азат Галимҗан улын – Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасарын (килешү буенча);

Иванов Сергей Евгеньевичны – «Татарстан Республикасында Стандартлаштыру, метрология һәм сынаулар дәүләт төбәк үзәге» федераль бюджет учреждениесе директорының метрология буенча урынбасарын (килешү буенча);

Кобелев Игорь Гелиевичны – Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасарын (килешү буенча);

Коробченко Олег Владимировичны – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрын;

Кузьмичева Елена Ивановнаны – «Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе» Берлеге рәисен (килешү буенча);

Мәүлетдинова Гөлнара Сафиулла кызын – «Идел буе федераль округы буенча Геология мәгълүматы территориаль фонды» федераль бюджет учреждениесенең Татарстан филиалы җитәкчесен (килешү буенча);

Минушев Тимур Рөстәм улын – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Икътисадый куркынычсызлык һәм коррупциягә каршы көрәшү идарәсе башлыгын (килешү буенча);

Олейник Павел Михайловичны – Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе җитәкчесенең беренче урынбасарын (килешү буенча);

Прокофьева Марина Викторовнаны – Кулланучылар хокукларын саклау һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесе урынбасарын (килешү буенча);

Сергеев Сергей Валентиновичны – Россия Федерациясе Гражданоборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе башлыгы урынбасарын (килешү буенча);

Скирда Максим Владимировичны – Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгын (килешү буенча);

Токарев Николай Анатольевичны – Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтенең атом-төш һәм радиация куркынычсызлыгы күзәтчелеге буенча Идел буе төбәкара территориаль идарәсе Чувашстан Республикасы, Марий Эл һәм Татарстан Республикаларындагы инспекцияләре төбәкара бүлеге башлыгын (килешү буенча);

Хәйруллин Альберт Тәүфикъ улын – Транспорт өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Дәүләт автомобиль юлы күзәтчелеге Урта Идел төбәкара идарәсе башлыгы урынбасарын (килешү буенча);

Шәйхетдинова Любовь Николаевнаны – Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы җитәкчесен (килешү буенча);

Шакиров Фаяз Фәнил улын – Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсе җитәкчесен (килешү буенча);

Яковенко Андрей Игоревичны – Җәзаларны үтәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы урынбасарын (килешү буенча).

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**